КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 5 сентябрь г.Казань № 664

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмалар белән идарә итүнең бердәм органын билгеләү турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 48 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмалар белән идарә итүнең бердәм органын билгеләү турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 48 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 24 март, 340 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертелергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 316 номерлы карары белән расланган Кече һәм урта эшкуарлыкка, шулай ук «Икътисадый үсеш һәм инновацион икътисад» Россия Федерациясе дәүләт программасының 48 нче кушымтасында китерелгән Россия Федерациясе субъектларында дәүләт ярдәменә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясен, аңа Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Нәтиҗәле һәм конкурентлы икътисад» илкүләм проекты

составына керүче «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» федераль проектының чараларны гамәлгә ашырганда чыгымнарның төп юнәлешләрен, чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга таләпләрне, дәүләт (муниципаль) микрофинанс оешмаларына һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләрне күздә тотучы максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче төбәк проектлары чараларын Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен таләпләрне раслау турында» 2025 елның 27 мартындагы 195 номерлы боерыгы белән расланган «Нәтиҗәле һәм конкурентлы икътисад» илкүләм проекты составына керүче «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» федераль проектының чараларны гамәлгә ашырганда чыгымнарның төп юнәлешләрен, чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга таләпләрне, дәүләт (муниципаль) микрофинанс оешмаларына һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләрне күздә тотучы максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче төбәк проектлары чараларын Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен таләпләрнең 3.3.1 пунктында күрсәтелгән функцияләрне биреп, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын төзүче оешмалар белән идарә итүнең бердәм органы итеп билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин